РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2025 елның 29 декабре** **Чистай шәһәре** **№6/3**

2026 елга Татарстан Республикасы
"Чистай муниципаль районы"
муниципаль берәмлеге милкендәге
мөлкәтне хосусыйлаштыруның
фаразлау планы (программасы) турында

"Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында" 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Чистай муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2026 елга Татарстан Республикасы "Чистай муниципаль районы" муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) кушымта нигезендә расларга.
2. 2026 елга Татарстан Республикасының "Чистай муниципаль районы" муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru), шулай ук торглар үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында (torgi.gov.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының Законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль
районы башлыгы Д.А. Иванов

Чистай муниципаль
районы Советының
2025 елның "29" декабрендәге
6/3 номерлы карарына
кушымта

**2026 елга Татарстан Республикасы "Чистай муниципаль районы" муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыру планы**

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасының "Чистай муниципаль районы" муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) 2026 елга "Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында" 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 10 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Чистай муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләнгән.

1.2. 2026 елда муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру муниципаль милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, күчемсез милек объектларын тотуга инвестицияләр җәлеп итүгә, муниципаль мөлкәтне сатудан бюджет кытлыгын каплау чыганакларын булдыруга юнәлдерелгән.

1.3. "Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында" 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруны аукционда яисә конкурста сату юлы белән һәм законда каралган башка ысуллар белән башкару күздә тотыла.

## 2 бүлек. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек

2.1. 2026 елда муниципаль казнадагы һәм Чистай муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган оешмалардан файдаланудагы муниципаль мөлкәт хосусыйлаштырылырга тиеш.

2.2. Хосусыйлаштыруга планлаштырыла торган муниципаль күчемсез мөлкәт исемлеге:

| № т/б | Объектның исеме | Урнашу урыны | Җир кишәрлеге кв.м. | | Хосусыйлаштыруның күздә | Керемнәр фаразымең сум |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Объект | Җир кишәрлег | | |
| 1 | Торак булмаган бина, мәктәп | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Чулпан авылы, Театр ур., 11-а йорт | 80,9 | 7 181 | 2026 елга | 100 |
| 2 | Торак булмаган бина, балалар бакчасы | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Югары Кондрата ав., Центральная ур., 37 йорт | 402,4 | 1 369 | 2026 елга | 300 |
| 3 | Торак булмаган | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Югары | 59,9 | 153 | 2026 | 50 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | бина, склад | Кондрата ав., Центральная ур., 37 йорт | | | елга | |
| 4 | Торак булмаган бина, мәктәп | Татарстан Республикасы, Чистай ш., Тукай ур., 17 йорт | 406,9 | - | 2026 елга | Объект өчен 1 сум |
| 5 | Торак булмаган бина, балалар бакчасы | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Татар Талкышы авылы, Совет ур., 5/1 йорт | 721,2 | 2 485,9 | 2026 елга | 250 |
| 6 | Торак булмаган бина | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Татар Талкышы авылы, Совет ур., 5/2 йорт | 46,3 | 81 | 2026 елга | 50 |
| 7 | Торак булмаган бина, мәктәп | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Ислэй авылы, Центральная ур. 20-б йорт | 401,9 | 2 523 | 2026 елга | 200 |
| 8 | Торак булмаган бина, котельный | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Ислэй авылы, Центральная ур. 20-б йорт | 63,4 | 93 | 2026 елга | 50 |
| 9 | Торак булмаган бина, остаханә | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Ислэй авылы, Центральная ур., 20-б йорт | 32,7 | 95 | 2026 елга | 30 |
| 10 | Торак булмаган бина, балалар бакчасы | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Түбән Кондрата авылы, 1 нче Май ур., 7а йорт | 480,9 | 2 459 | 2026 елга | 250 |
| 11 | Торак булмаган бина, мәктәп | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Чирүле Шонталы авылы, Речная ур., 3а йорт | 77,1 | - | 2026 елга | 100 |
| 12 | Торак булмаган бина, төзелеш материаллары склады | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Чистай ш., Учхоз тыкрыгы, 12Е йорт | 95 | - | 2026 елга | 100 |
| 13 | Торак булмаган бина, ГСМ склады | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Чистай ш., Учхоз тыкрыгы, 12Е йорт | 44,7 | - | 2026 елга | 50 |
| 14 | Торак булмаган бина, үтеп йөрү юлы | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Чистай ш., Учхоз тыкрыгы, 12Е йорт | 29,7 | - | 2026 елга | 50 |
| 15 | Торак булмаган бина, | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Чистай ш., Учхоз тыкрыгы, 12Е йорт | 119,7 | - | 2026 елга | 150 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | лаборатория бинасы | | | | | |
| 16 | Торак булмаган бина, гараж | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Чистай ш., Учхоз тыкрыгы, 12Е йорт | 177,5 | - | 2026 елга | 200 |
| 17 | Торак булмаган бина, гараж | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Чистай ш., Учхоз тык., 12Д йорт | 86,3 | 2982 | 2026 елга | 100 |
| 18 | Торак булмаган бина, фельдшер-акушерлык пункты | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Кубас авылы, Озерная ур., 9 йорт | 194,5 | 1807 | 2026 елга | 500 |
| 19 | Торак булмаган бина, балалар бакчасы | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Яуширмә авылы, Г.Исхакый ур., 16 йорт | 463,6 | 2468 | 2026 елга | 500 |
| 20 | Торак булмаган бина, балалар бакчасы | ТР, Чистай районы, Түбән Кондрата ав., 1 нче Май ур., 7а йорт | 480,9 | 2459 | 2026 елга | 500 |

2.3. 2026 елда муниципаль милектәге муниципаль унитар предприятиеләрне һәм акцияләрне хосусыйлаштыру планлаштырылмый.

2.4. Муниципаль мөлкәтне, шул исәптән мондый мөлкәт белән һәм алардан файдалану өчен кирәкле җир кишәрлекләрен сатып алучыга бер үк вакытта сатыла торган мөлкәтне хосусыйлаштыру турындагы карар Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы карарлары нигезендә Чистай муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе тарафыннан кабул ителә.

**3 бүлек. Муниципаль милекне хосусыйлаштыруны мәгълүмати тәэмин итү**

3.1. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында мәгълүматны оператив бирү һәм киңрәк реклама белән тәэмин итү максатларында Чистай муниципаль районы Җир һәм мөлкәт палатасы әлеге фаразлау планын үтәү барышында рәсми мәгълүмат чыганакларыннан тыш башка массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәтләреннән файдаланырга хокуклы.